Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

« 18 » декабрь 2017 ел № 5

**Арча шәһәр Советының 29.11.2012 № 58 карары (01.11.2016 №48 үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәр Советының 07.07.2009 №426 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, хокукны тәэмин итү максатларында шәһәр җирлеге халкын муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнаштырга карар итәм:

1.2018 елның 21 февраленә Арча шәһәр Советының 29.11.2012 № 58 (01.11.2016 №48 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2.Арча шәһәр Советының 29.11.2012 №58 (01.11.2016 №48 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Арча шәһәр Советының карары проекты буенча гавами тыңлауларны 21.02.2018 елда 15.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, кисәтүләре һәм гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 21.02.2018 елда 15.00 сәгатькә кадәр ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча язмача җибәрелә дип билгеләргә, тел. 8 (84366) 3-16-25.

4.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советының әлеге карарын һәм карар проектын (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф.Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И. Г. Нуриев